**Татарстан Республикасы Буа шәһәре территориаль сайлау комиссиясе**
**(ИКМО вәкаләтләре белән)**

# К А Р А Р

19 ноябрь 2018 ел 1-6

**2018 елның 18 ноябрендә Буа муниципаль районы Буа шәһәре территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 56 статьясы нигезендә, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләре беркетмәләренең беренче нөсхәләре күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасы Буа шәһәренең территория сайлау комиссиясе (ИКМО) 2018 елның 19 ноябрендә 2018 елның 18 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында түбәндәгеләр хакында беркетмә төзеде:

Тавыш бирү тәмамланган вакытка референдумда катнашучылар исемлекләренә 16489 катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучылар саны - 10511, бу муниципаль берәмлек территориясендә референдумда катнашучылар исемлекләренә кертелгән референдумда катнашучыларның 63,75 процентын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен референдумда катнашучыларның 7971 (75,83%) тавыш бирде, бу тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучыларның 50 проценттан артыгын тәшкил итә; «Юк» позициясе өчен 2496 референдумда катнашучы тавыш бирде, бу 23,75 % тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Буа шәһәренең территория сайлау комиссиясе (ИКМО) карар итте:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре территориясендә 2018 елның 18 ноябрендә узган референдумны, референдум нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «ТР Буа муниципаль районы Буа шәһәре территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм җирле референдумда катнашу хокукына ия булган 18 яше тулган һәр гражданиннан 2019 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә –тротуарлар төзү өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Җирле референдумның нәтиҗәләрен «Байрак» («Байрак», «Ялав») район газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Буа муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Буа шәһәренең
территориаль сайлау комиссиясе (ИКМО) рәисе Ш.Н. Садриев

Татарстан Республикасы Буа шәһәренең
территориаль сайлау комиссиясе (ИКМО) секретаре Р.Н. Вәлиева